СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**01 ноябрь 2024ел** **№13**

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шекә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шекә авылында Шекә авылы, Свердлов урамы, 19 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шекә авылында Шекә авылы, Свердлов урамы, 19 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Ворошилов, Свердлов урамында яшәүчеләр.

2нче этап: Коммуна, Октябрь урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шекә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, Шекә авылы Коммуна һәм Свердлов урамнары арасында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Шекә авылында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән 25 яктырткыч сатып алу һәм урнаштыру);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (Шекә авылындагы зират территориясеннән агачларны санитар кисү һәм чыгару)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

5. Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шекә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Шекә авылы, Ворошилов урамы, 2 йорт, Ворошилов урамы, 17а йорт адреслары буенча, Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1121690000210 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ * ИНН 1609012678